**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань / Казан ш. **БОЕРЫК**

01.07.2026 704-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Ясачка (Озын күл), Сушка (Ямбакты чокыры), Салманка (Салман инеше), Нохратка, Ромоданка (Актай елгасы кушылдыгы), Тарла, Багражка (Чишмә елгасы кушылдыгы) елгаларының су саклау зоналарын һәм яр буе яклау полосаларын билгеләү турында

Рәсәй Федерациясе Су кодексының 65 статьясы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы, Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 31 октябрендәге № 1459 карары белән расланган Су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү Кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 06.07.2005 ел, № 325 карары белән һәм 22.04.2025 ел, № 2025.003 «Татарстан Республикасы Алексеевск, Әлмәт, Әлки, Әлмәт, Спас, Нурлат муниципаль районнары территориясендә урнашкан Ясачка (Озын күл), Сушка (Ямбакты чокыры), Салманка (Салман инеше), Нохратка, Ромоданка (Актай елгасы кушылдыгы), Тарла, Багражка (Чишмә елгасы кушылдыгы) елгаларының яр буе сызыклары (су объектлары чикләре), су саклау зоналары чикләре һәм яр буе яклау полосалары чикләре урнашу урынын билгеләү» контракт кысаларында башкарылган эшләр йомгаклары буенча, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналарының һәм яр буе яклау полосаларының киңлеген, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә билгеләргә:

1.1. Ясачка елгасы (Озын күл):
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.2. Сушка елгасы (Ямбакты чокыры):
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.3. Салманка елгасы (Салман инеше):
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.4. Нохратка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.5. Ромоданка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.6. Тарла елгасы:
су саклау зонасының киңлеге - 50 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.

1.7. Багражка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (А.Р. Гыйззәтуллина) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Ясачка (Озын күл), Сушка (Ямбакты чокыры), Салманка (Салман инеше), Нохратка, Ромоданка (Актай елгасы кушылдыгы), Тарла, Багражка (Чишмә елгасы кушылдыгы) елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе яклау полосалары чикләре турында белешмәләр җибәрергә.

2.1 билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен су ресурсларының федераль агентлыгына;

2.2 территорияләренә карата су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләре билгеләнә торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына;

2.3 Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органы) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү өчен.

3. Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В. Веселова) әлеге боерыкны татарчага тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (Р.А. Заһидуллин) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары О.В. Мандичевага йөкләргә.

Министр А.И. А.И. Җиһаншин